ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 591-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 591-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 46-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының 346.20 статьясындагы 1.1 һәм 2.1 пунктлары үз көчләрен югалткан дип танылды. Әлеге пунктларның гамәлдә булуы салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы, хисап (салым) чоры нәтиҗәләре буенча керемнәре 150 млн. сумнан артып киткән, әмма 200 млн. сумнан артмаган һәм (яисә) хезмәткәрләрнең уртача саны 100 кешедән артып киткән, ләкин 130 кешедән артмаган салым түләүчеләргә кагылды, салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга хокукны сакларга мөмкинлек бирде. Шул ук вакытта, йомгаклары буенча арттыру рөхсәт ителгән кварталдан башлап, салым түләүчеләрнең мондый категориясе өчен салым ставкалары «керемнәр» салым салу объекты буенча 8% күләмендә (6% урынына) һәм «чыгымнар күләменә киметелгән керемнәр» салым салу объекты буенча 20% итеп (15% урынына), арттырылган күләмдә билгеләнде.

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.